**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 9 март | № 133

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган гражданнарга социаль хезмәтләр күрсәтүне камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлекнең беренче һәм икенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына, чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга, качакларга (алга таба – гражданнар, граждан) Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүне регламентлаштыра.

Бу Тәртипнең гамәле, Татарстан Республикасында картлар һәм инвалидлар өчен интернат йортларда (пансионатларда), картлар һәм инвалидлар өчен махсус

интернат йортларда, билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыле булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү өлешендә шулай ук ашыгыч массакүләм тәртиптә Россия Федерациясе территориясенә килгән һәм Россия Федерациясе территориясендә качак буларак тану турында үтенеч белән мөрәҗәгать иткән Украина гражданнары арасыннан булган затларга һәм Украина территориясендә даими яшәүче гражданлыгы булмаган затларга тарала.»;

1.6.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 8 – 10 пунктчалар өстәргә:

«8) Асылда Россия Федерациясе территориясендә качак буларак тану турында үтенечне карап тикшерү турында таныклыкның, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча качу урыны бирү турында гаризаны карап тикшерү хакында белешмәнең яки Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча качу урыны бирү турында таныклыкның гамәлдә булу вакыты чыгу, әгәр аларның гамәлдә булуы вакыты чыккан көнгә кадәр тиешенчә качак таныклыгы бирелмәсә, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча качу урыны бирү турында таныклык яки гамәлдә булу вакыты озайтылган Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча качу урыны бирү турында таныклык;

9) социаль хезмәтләрне алучының качак статусын югалтуы яки аны бу статустан мәхрүм итү;

10) социаль хезмәтләрне алучының вакытлыча качу урынын югалтуы яки бу урыннан мәхрүм итү.»;

1.6 бүлекчәгә түбәндәге эчтәлекле 1.6.2 пункт өстәргә:

«1.6.2. Социаль хезмәтләрне алучылар үзләренең социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә медицина каршылыклары барлыкка килгәндә, бу хакта вәкаләтле медицина оешмасы тарафыннан тиешле бәяләмә төзелү турында билгеле булган көндә, әмма аны алган көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча социаль хезмәтләр күрсәтүчегә хәбәр итәргә тиеш.

I бүлекнең икенче абзацында күрсәтелгән социаль хезмәтләрне алучылар социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчегә 1.6.1 пунктның 9 һәм 10 пунктчаларында күрсәтелгән шартлар барлыкка килү турында, әлеге шартлар барлыкка килгән көндә хәбәр итәргә тиеш.»;

7.1.1 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2. | Шәхесне таныклый торган документ (булганда) | Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары | законнар нигезендә». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\133.docx